ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

31 июль 2015 ел

**КАРАР**

№ 4351

Муниципаль милектәге җир участогын сатулар үткәрмичә сату буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

Россия Федерациясе Җир кодексының 39.3 статьясының 2 пункты, 39.14 статьясы, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы, Башкарма комитетның «Муниципаль һәм дәүләт хезмәтләре исемлеген раслау турында» 2013 елның 9 апрелендәге 2393 номерлы карары, Башкарма комитетның 2011 елның 30 мартындагы 1576 номерлы карары белән расланган Башкарма комитет тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләрнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында нигезләмә нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Муниципаль милектәге җир участогын сатулар үткәрмичә сату буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын кушымтада каралганча расларга.

2. Җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.М. Кудряшовага «Интернет» челтәрендә тиешле мәгълүмат системаларында һәм Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыру өчен, Муниципаль милектәге җир участогын сатулар үткәрмичә сату буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын «Мәгълүмати технологияләр үзәге» МАУга бирүне тәэмин итәргә.

Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары Р.Ә. Абдуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

Н.Г. Мәһдиев

Башкарма комитетның
2015 елның 31 июлендәге
4351 номерлы карарына
кушымта

Муниципаль милектәге җир участогын
сатулар үткәрмичә сату буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең
административ регламенты

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (алга таба – Регламент) Муниципаль милектәге җир участогын сатулар үткәрмичә сату буенча муниципаль хезмәт (алга таба – муниципаль хезмәт) күрсәтү стандартын һәм тәртибен билгели.

Әлеге Регламентның гамәлдә булуы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендәге муниципаль милектәге җир участокларына һәм дәүләт милке чикләнмәгән җир участокларына кагыла.

1.2. Муниципаль хезмәттән файдаланучылар (алга таба – гариза бирүче): Россия Федерациясе Җир кодексының 39.3 статьясының 2 пунктында санап үтелгән физик һәм юридик затлар (1 нче кушымта).

1.3. Муниципаль хезмәт Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты (алга таба – Башкарма комитет) тарафыннан күрсәтелә.

Муниципаль хезмәтне башкаручы – Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе (алга таба – ҖММИ).

1.3.1. Башкарма комитетның урнашу урыны: Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре, Хәсән Туфан проспекты, 23 йорт.

ҖММИнең урнашу урыны: Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре, Хәсән Туфан проспекты, 23 йорт, 233 кабинет.

Башкарма комитетның эш графигы:

дүшәмбе – җомга: 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр, төшке аш вакыты: 12.00 дән 13.00 сәгатькә кадәр.

шимбә, якшәмбе: ял көннәре;

ҖММИнең белешмә телефоны: 30-55-54.

Башкарма комитет бинасына керү шәхесне раслаучы документлар буенча.

1.3.2. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (алга таба – «Интернет» челтәре) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайты адресы: (http:/ www.nabchelny.ru).

1.3.3. Муниципаль хезмәт турында мәгълүматны алырга мөмкин:

1) гариза бирүчеләр белән эшләү өчен Башкарма комитет бүлмәләрендә урнашкан муниципаль хезмәт турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган мәгълүмат стендлары ярдәмендә;

2) «Интернет» челтәре аша Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында (http:/ www.nabchelny.ru.);

3) Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatar.ru);

4) Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталында (http:/www.gosuslugi.ru);

5) Башкарма комитетта (ҖММИ):

- телдән мөрәҗәгать иткәндә - шәхсән яки телефон буенча;

- язмача (шул исәптән электрон документ формасында) мөрәҗәгать иткәндә – кәгазьдә почта аша, электрон формада электрон почта (uzioIP@yandex.ru) аша.

1.3.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү мәсьәләләре буенча мәгълүмат ҖММИ белгече тарафыннан Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында һәм гариза бирүчеләр белән эшләү өчен Башкарма комитет бүлмәләрендәге мәгълүмат стендларында урнаштырыла.

1.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәге документлар нигезендә гамәлгә ашырыла:

1) Россия Федерациясе Граждан кодексы 30.11.1994 №51-ФЗ (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 05.12.1994, №32, ст. 3301) (алга таба – РФ Граждан кодексы);

2) Россия Федерациясе Җир кодексы 25.10.2001 №136-ФЗ (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 29.10.2001, №44, ст. 4147) (алга таба – РФ Җир кодексы);

3) «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында» 2001 елның 25 октябрендәге 137-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 29.10.2001, N 44, ст. 4148) (алга таба – 137-ФЗ номерлы Федеральный закон);

4) «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 02.08.2010, № 31, ст. 4179) (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон);

5) «Күчемсез милекнең дәүләт кадастры турында» 2007 елның 24 июлендәге 221-ФЗ номерлы Федераль закон. (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 30.07.2007, №31, ст. 4017) (алга таба – 221-ФЗ номерлы Федераль закон);

6) «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон (РФ законнары җыентыгы, 06.10.2003, №40, ст. 3822 ) (алга таба – 131-ФЗ номерлы Федераль закон);

7) «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (Татарстан Республикасы, №155-156, 03.08.2004) (алга таба – 45-ТРЗ номерлы ТР Законы);

8) Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Гариза бирүченең җир участогын сатулар үткәрмичә сатып алуга хокукын раслый торган документлар исемлеген раслау турында» 2015 елның 12 гыйнварындагы 1 номерлы боерыгы (Рәсми хокукый мәгълүмат интернет-порталы http://www.pravo.gov.ru, 28.02.2015) (алга таба – 1 номерлы Боерык);

9) «Яр Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге Вәкиллекле органының 2005 елның 8 декабрендәге 6/5 номерлы Карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы (алга таба – шәһәр Уставы);

10) Башкарма комитетның «Муниципаль һәм дәүләт хезмәтләре исемлеген раслау турында» 2013 елның 9 апрелендәге 2393 номерлы карары (алга таба – 2393 номерлы карар);

11) Башкарма комитет Җитәкчесенең 2008 елның 17 декабрендәге 1259 номерлы боерыгы белән расланган Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе турында нигезләмә (алга таба – Идарә турында нигезләмә);

12) Башкарма комитетның 2014 елның 11 мартындагы 147-р номерлы боерыгы белән расланган Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитетының эш регламенты (алга таба – Эш регламенты);

13) Башкарма комитет Җитәкчесенең 2007 елның 16 июлендәге 754 номерлы боерыгы белән расланган Эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре (алга таба – Эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре).

1.5. Әлеге Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

техник хата – муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән һәм документка (муниципаль хезмәт нәтиҗәсенә) кертелгән мәгълүматларның бу мәгълүматларны кертүгә нигез булган документлардагы мәгълүматларга туры килмәвенә китергән хата (язудагы хата, басмадагы хата, грамматик яки арифметик хата яисә шуңа охшаш хата).

Муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза дигәндә (алга таба – гариза) муниципаль хезмәт күрсәтү турында запрос аңлашыла (210-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясының 2 пункты). Гариза әлеге Регламентка 2 нче кушымта нигезендә стандарт бланкта тутырыла.

## 2. Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты

| Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартына таләпнең исеме | Стандартка карата таләпләрнең эчтәлеге | Хезмәтне яки таләпне билгели торган норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Муниципаль хезмәтнең исеме | Муниципаль милектәге җир участогын сатулар үткәрмичә сату | 2393 номерлы карар;<br>РФ Җир кодексының 39.3 статьясы |
| 2.2. Турыдан-туры муниципаль хезмәт күрсәтүче җирле үзидарә органының исеме | Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты исеменнән җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе | 210-ФЗ номерлы Федераль законның 6 статьясы;<br>РФ Җир кодексының 39.2 статьясы;<br>шәһәр Уставының 41 статьясы |
| 2.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау | Җир участогын сату-алу шартнамәсе, җир участогын кабул итү-тапшыру акты.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат | РФ җир кодексының 39.14 статьясындагы 1 пунктының 7 пунктчасы;<br>РФ Граждан кодексының 218 статьясы |
| 2.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы | Гариза кергән көннән башлап 30 көннән артык түгел | РФ Җир кодексының 39.17 статьясының 5 пункты |
| 2.5. Муниципаль хезмәт, шулай ук муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булып торган хезмәтләр күрсәтү өчен закон яки башка норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге | 1) Гариза (2 нче кушымта);<br>2) гариза бирүченең сатулар үткәрмичә җир участогын алу хокукын раслаучы һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнгән исемлектә каралган документлар, ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә вәкаләтле органга тапшырылырга тиешле документлардан тыш;<br>3) гариза бирүче вәкиленең вәкаләтләрен раслаучы документ, гариза белән гариза бирүченең вәкиле мөрәҗәгать | РФ Җир кодексының 39.17 статьясы;<br>1 номерлы Боерык |

| | | |
|---|---|---|
| | иткән очракта;<br>4) чит ил дәүләте законнары нигезендә юридик затны дәүләт теркәвенә алу турындагы документларның таныкланган рус теленә тәрҗемәсе, гариза бирүче булып чит ил юридик заты торган очракта.<br>Муниципаль хезмәттән файдаланучының категориясенә бәйле рәвештә, гариза бирүче тарафыннан бирелә торган өстәмә документлар исемлеге 3 нче кушымтада китерелгән. | |
| 2.6. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагындагы һәм гариза бирүче тапшырырга хокуклы документларның тулы исемлеге | Муниципаль хезмәттән файдаланучылар категориясенә бәйле рәвештә, документлар исемлеге 3 нче кушымтада китерелгән | 1 номерлы Боерык |
| 2.7. Норматив хокукый актларда каралган очракларда, муниципаль хезмәт күрсәтү (муниципаль хезмәт күрсәтүче җирле үзидарә органы тарафыннан гамәлгә ашырыла) өчен килештерү таләп ителә торган дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм аларның структур бүлекчәләре исемлеге. | 1) Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе<br>2) Башкарма комитетның архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе;<br>3) Башкарма комитетның хокук идарәсе;<br>4) Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсе. | Эш регламентының 3 бүлеге |
| 2.8. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тартуның нигезләренең тулы исемлеге | 1) Гариза әлеге Регламентның 2 нче кушымтасында билгеләнгән формага туры килми;<br>2) гариза тиешле булмаган органга тапшырылу;<br>3) гаризага әлеге Регламентның 2.5 пунктында | РФ Җир кодексының 39.17 статьясының 3 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| | нигезендә документлар теркәлмәгән | |
| 2.9. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату яки баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Кире кагу өчен нигезләр:<br>1) җир участогы бирү турындагы гариза белән җир законнары нигезендә, җир участогын сатулар үткәрмичә сатып алуга хокукы булмаган зат мөрәҗәгать иткән;<br>2) җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогы даими (сроксыз) файдалануга, түләүсез файдалануга, гомерлек мирас итеп биләү яки аренда хокукында бирелгән (җир участогы бирү турындагы гариза белән әлеге хокукларга ия булган зат мөрәҗәгать иткән очраклардан тыш);<br>3) җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогында гражданнарга яки юридик затларга караган бина, корылма, төзелеше тәмамланмаган объект урнашкан (җир участогы бирү турындагы гариза белән әлеге биналарның, корылмаларның милекчесе мөрәҗәгать иткән очраклардан тыш);<br>4) җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогында дәүләт яки муниципаль милектәге бина, корылма, төзелеше тәмамланмаган объект урнашкан;<br>5) җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогы әйләнештән алынган яки әйләнештә чикләнгән һәм милек хокукында аны бирү рөхсәт ителми;<br>6) җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогы дәүләт яки муниципаль ихтыяҗлар өчен резервланган;<br>7) җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогы төзелгән территорияне үстерү турында башка зат белән шартнамә төзелгән территория чикләрендә урнашкан;<br>8) җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогы төзелгән территорияне үстерү турында башка зат белән шартнамә төзелгән территория чикләрендә урнашкан яки җир участогы төзелгән территорияне | РФ Җир кодексының 39.16 статьясы |

| | | |
|---|---|---|
| | комплекслы үзләштерү турында башка зат белән шартнамә төзелгән җир участогыннан барлыкка килгән;<br>9) җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогы, төзелгән территорияне комплекслы үзләштерү турында яки төзелгән территорияне үстерү турында башка зат белән шартнамә төзелгән җир участогыннан барлыкка килгән һәм территорияне планлаштыру буенча расланган документлар нигезендә федераль әһәмияткә ия объектларны, региональ әһәмияткә объектларны яки җирле әһәмияткә ия объектларны урнаштыру өчен билгеләнгән;<br>10) җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогы, аукцион үткәрү турындагы хәбәр РФ Җир кодексының 39.11 статьясының 19 пункты нигезендә урнаштырылган аукционның предметы булып тора;<br>11) җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогына карата аны сату буенча аукцион яки аны арендалау шартнамәсе төзү хокукына аукцион үткәрү турында РФ Җир кодексының 39.11 статьясының 4 пункты 6 пунктчасында каралган гариза кергән, андый җир участогы РФ Җир кодексының 39.11 статьясының 4 пунктның 4 пунктчасы нигезендә барлыкка килгән һәм вәкаләтле орган тарафыннан РФ Җир кодексының 39.11 статьясының 8 пунктында каралган нигезләр буенча әлеге аукцион үткәрүне кире кагу турында карар кабул ителмәү шарты белән;<br>12) җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогына карата индивидуаль торак төзелеше, шәхси ярдәмче хуҗалык, бакчачылык, дача хуҗалыгы алып бару өчен җир участогы бирү турындагы хәбәр РФ Җир кодексының 39.18 статьясындагы 1 пунктның 1 пунктчасы нигезендә басылып чыгу һәм урнаштырылган;<br>13) җир участогыннан рөхсәт ителгән файдалану андый җир участогыннан файдалануның җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән максатларына туры килми;<br>14) яшелчәчелек, бакчачылык алып бару өчен | |

| | | |
|---|---|---|
| | гражданнар тарафыннан төзелгән коммерцияле булмаган оешмага җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогының мәйданы федераль законнар нигезендә билгеләнгән чик күләменнән артып китә;<br>15) җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогы территориаль планлаштыруның расланган документлары һәм (яки) территорияне планлаштыру документлары нигезендә федераль әһәмияткә ия объектларны, региональ әһәмияткә ия объектларны яки җирле әһәмияткә ия объектларны урнаштыру өчен билгеләнгән;<br>16) җир участогын хокукларның әлеге төрендә бирү рөхсәт ителми;<br>17) җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогына карата рөхсәт ителгән файдалану төре билгеләнмәгән;<br>18) җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогы аерым категория җиргә кертелмәгән;<br>19) җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогына карата аны бирүне алдан килештерү турында карар кабул ителгән һәм аның гамәлдә булу срогы чыкмаган һәм җир участогын бирү турында гариза белән әлеге карарда күрсәтелмәгән зат мөрәҗәгать иткән;<br>20) җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогы дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен кире алынган;<br>21) җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогының чикләре «Күчемсез милекнең дәүләт кадастры турында» Федераль закон нигезендә төгәлләштерелергә тиеш;<br>22) җир участогы бирү турындагы гаризада күрсәтелгән җир участогының мәйданы җир участогының урнашу схемасында, территорияне межалау проектында яки урман участокларының урнашу урыны, чикләре, мәйданы турында һәм башка сан һәм сыйфат характеристикалары турында проект документларында (алар нигезендә ун проценттан | |

| | | |
|---|---|---|
| | артык күләмдә шундый җир участогы барлыкка китерелгән) күрсәтелгән мәйданнан артып китә | |
| 2.10. Дәүләт пошлинасы яки муниципаль хезмәт күрсәтү өчен алына торган башка түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Муниципаль хезмәт түләүсез нигездә күрсәтелә | |
| 2.11. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү өчен түләү күләмен исәпләү методикасы турында мәгълүматны да кертеп, мондый түләүне алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.12. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында запрос биргәндә һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь срогы | Чират булганда муниципаль хезмәттән файдалануга гариза бирү – 15 минуттан артык түгел.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь срогы 15 минуттан артырга тиеш түгел | |
| 2.13. Гариза бирүченең муниципаль хезмәт күрсәтү турында запросын теркәү срогы | Гариза кергән вакыттан башлап бер көн эчендә | |
| 2.14. Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга карата таләпләр | Бина запрос тутыру өчен өстәл һәм урындыклар, запросны тутыру үрнәкләре һәм муниципаль хезмәттән файдалану өчен кирәкле документлар исемлеге булган мәгълүмат стендлары белән җиһазландырылган. | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.15. Муниципаль хезмәттән һәркем файдалана алырлык булу һәм сыйфат күрсәткечләре, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәткәндә гариза бирүченең вазыйфаи затлар белән хезмәттәшлеге саны һәм аларның дәвамлылыгы, дәүләт хезмәтен дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәктә алу мөмкинлеге | Муниципаль хезмәттән һәркем файдалана алырлык булу күрсәткечләре булып түбәндәгеләр тора:<br>Башкарма комитет бинасының җәмәгать транспортыннан файдалану зонасында урнашы;<br>кирәкле сандагы белгечләр, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул итү гамәлгә ашырыла торган бүлмәләр булу;<br>мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендә шәһәрнең рәсми сайтында, Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында муниципаль хезмәт күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булу.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү сыйфаты түбәндәгеләр булмау белән характерлана:<br>документлар кабул иткәндә һәм гариза бирүчеләргә документлар биргәндә чиратлар;<br>муниципаль хезмәт күрсәтү срокларын бозулар;<br>муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләр булмау;<br>муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең гариза бирүчеләргә карата тупас, игътибарсыз мөнәсәбәтенә шикаятьләр.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү турында запрос биргәндә һәм муниципаль хезмәт нәтиҗәсен алганда муниципаль хезмәт күрсәтүче вазыйфаи затның һәм гариза бирүченең бер тапкыр үзара эшчәнлеге күздә тотыла. Үзара эшчәнлек дәвамлылыгы әлеге Регламент белән билгеләнә.<br>Муниципаль хезмәт дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәктә (алга таба – КФҮ) күрсәтелгәндә, консультация бирүне, документлар кабул итүне һәм бирүне КФҮ белгече гамәлгә ашыра. | |
| 2.16. Электрон формада муниципаль хезмәт күрсәтү | Муниципаль хезмәттән электрон формада файдалану тәртибе турында консультацияне Интернет-кабул итү | |

| | | |
|---|---|---|
| үзенчәлекләре | бүлмәсе яки Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша алырга мөмкин.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү турында гаризаны электрон формада бирү законда каралган очракта, гариза Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре порталы (http://uslugi. tatar.ru/) яки Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы (http:// www.gosuslugi.ru/) аша бирелә. | |

## 3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм сроклары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән электрон формада административ процедураларны үтәү үзенчәлекләре, шулай ук күпфункцияле үзәкләрдә административ процедураларны башкару үзенчәлекләре

3.1. Муниципаль хезмәт күрсәткәндә гамәлләрнең эзлеклелеген тасвирлау

3.1.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) гариза бирүчегә консультация бирү;

2) гаризаны һәм документларны кабул итү һәм теркәү;

3) ведомствоара запрослар формалаштыру һәм муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнаша торган органнарга җибәрү;

4) муниципаль хезмәт нәтиҗәсен әзерләү;

5) гариза бирүчегә муниципаль хезмәт нәтиҗәсен бирү.

3.1.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелегенең блок-схемасы әлеге Регламентка 4 нче кушымтада күрсәтелгән.

3.2. Гариза бирүчегә консультацияләр бирү

3.2.1. Гариза бирүче муниципаль хезмәттән файдалану тәртибе турында консультацияләр алу өчен Башкарма комитетка шәхсән, телефон һәм (яисә) электрон почта аша мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

ҖММИ белгече гариза бирүчегә консультация бирә, шул исәптән муниципаль хезмәттән файдалану өчен тапшырыла торган документларның составы, формасы һәм башка мәсьәләләр буенча һәм кирәк булганда, гариза бланкын тутыруда ярдәм күрсәтә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: тапшырыла торган документларның составы, формасы һәм муниципаль хезмәттән файдалануның башка мәсьәләләре буенча консультацияләр.

3.3. Гаризаны кабул итү һәм теркәү

3.3.1. Гариза бирүче шәхсән яки аның тарафыннан вәкаләтләнгән зат, әлеге Регламентның 2.5 пункты нигезендә документлар теркәп, Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә (алга таба – эш кәгазләрен алып бару идарәсе) муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) бирә.

Муниципаль хезмәт күрсәтү турында электрон формадагы гариза Башкарма комитетка электрон почта яисә интернет-кабул итү бүлмәсе аша җибәрелә. Электрон формада кергән гаризаны теркәү билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

Эш кәгазьләрен алып бару идарәсе белгече гамәлгә ашыра:

1) гариза бирүченең шәхесен билгелүне;

2) гариза бирүченең вәкаләтләрен тикшерүне (ышаныч язуы буенча эш иткән очракта);

3) тапшырылган документларның билгеләнгән таләпләргә туры килүен (документларның күчермәләрен тиешенчә рәсмиләштерү, документларда бозып язулар, өстәп язулар, сызылган сүзләр булмау) тикшерүне.

Кимчелекләр булмаган очракта, эш кәгазьләрен алып бару идарәсе белгече гамәлгә ашыра:

1) гаризаны кабул итүне һәм махсус журналда теркәүне;

2) гариза бирүчегә документларны кабул итү датасы, беркетелгән керү номеры, муниципаль хезмәтне башкару датасы һәм вакыты турында билгеләп, гаризаның күчермәсен тапшыруны;

3) гаризаны һәм документларны карап тикшерү өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрүне.

Әлеге Регламентның 2.8 пункты нигезендә документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булган очракта, эш кәгазьләрен алып бару идарәсенең гаризалар кабул итүче белгече гариза бирүчегә гаризаны теркәү өчен каршылыклар булу турында хәбәр итә һәм, гаризаны кире кайтару сәбәпләрен күрсәтеп, аңа документларны кире кайтара.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гамәлгә ашырыла:

1) гаризаны һәм документларны кабул итү – 15 минут эчендә;

2) гаризаны теркәү – гариза кергән вакыттан башлап бер эш көне эчендә.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән, карап тикшерү өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрелгән гариза һәм документлар яки гариза бирүчегә кире кайтарылган гариза һәм документлар.

3.3.2. Башкарма комитет Җитәкчесе гариза һәм документларны карап тикшерә һәм аларны, карап тикшерү өчен, Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасарына җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гариза һәм документлар кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: карап тикшерү өчен Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасарына җибәрелгән гариза һәм документлар.

3.3.3. Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары гаризаны һәм документларны карап тикшерә һәм аларны ҖММИ башлыгына җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гариза һәм документлар кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: ҖММИ башлыгына җибәрелгән гариза һәм документлар.

3.3.4. ҖММИ башлыгы гаризаны һәм документларны карап тикшерә һәм аларны ҖММИнең җир ресурслары белән идарә итү бүлеге башлыгына (алга таба – ҖММИ бүлеге башлыгы) җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гариза һәм документлар кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: ҖММИ бүлеге башлыгына җибәрелгән гариза һәм документлар.

3.3.5. ҖММИ бүлеге башлыгы гаризаны һәм документларны карап тикшерә һәм аларны ҖММИнең җир ресурслары белән идарә итү бүлеге белгеченә җибәрә (алга таба – ҖММИ бүлеге белгече).

Срок – 1 көн.

Процедураның нәтиҗәсе: ҖММИ бүлеге белгеченә җибәрелгән гариза һәм документлар.

3.4. Ведомствоара запрослар формалаштыру һәм муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү

3.4.1. ҖММИ бүлеге белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

норматив хокукый базаны исәпкә алып, гаризаны һәм документларны карап тикшерүне;

2) әлеге Регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән документларны бирү турында запрослар формалаштыруны һәм ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә электрон формада җибәрүне.

Срок – 1 көн.

Процедураның нәтиҗәсе: электрон формада җибәрелгән ведомствоара запрослар.

3.4.2. Мәгълүматлар белән тәэмин итүчеләрнең белгечләре, ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша кергән запрослар нигезендә, сорала торган документларны (мәгълүматны) бирә яки муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документ һәм (яки) мәгълүматның булмавы турында белдерү кәгазе җибәрә (алга таба – баш тарту турында белдерү кәгазе).

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар ведомствоара запрос документ һәм мәгълүмат бирә торган органга яки оешмага кергән көннән башлап биш эш көне эчендә гамәлгә ашырыла, әгәр ведомствоара запроска җавапны әзерләүнең һәм җибәрүнең башка сроклары федераль законнар, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең хокукый актлары һәм федераль законнар нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары белән билгеләнмәгән булса.

Процедураларның нәтиҗәсе: документлар (мәгълүматлар) яисә ҖММИ бүлеге белгеченә җибәрелгән баш тарту турында белдерү кәгазьләре.

3.5. Муниципаль хезмәт нәтиҗәсен әзерләү һәм гариза бирүчегә бирү

3.5.1. ҖММИ бүлеге белгече кергән документлар (мәгълүматлар) нигезендә гамәлгә ашыра:

1) карар проектын әзерләүне:

- җир участогын сату-алу шартнамәсе проектын (алга таба – шартнамә проекты);

- әлеге Регламентның 2.9 пунктында каралган нигезләр буенча муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат (алга таба – баш тарту турында хат);

2) килештерү өчен, баш тарту турында хатны яисә шартнамә проектын ҖММИ бүлеге башлыгына җибәрүне.

Срок – 3 көн.

Процедураның нәтиҗәсе: килештерү өчен ҖММИ бүлеге башлыгына җибәрелгән баш тарту турында хат яисә шартнамә проекты.

3.5.2. ҖММИ бүлеге башлыгы баш тарту турында хатны карап тикшерә, килештерә һәм имзалау өчен ҖММИ башлыгына җибәрә яисә шартнамә проектын килештерә һәм килештерү өчен ҖММИ башлыгына җибәрә.

Срок – 2 көн.

Процедураның нәтиҗәсе: ҖММИ башлыгына имзалау өчен җибәрелгән баш тарту турында хат яисә килештерү өчен җибәрелгән шартнамә проекты.

3.5.3. ҖММИ башлыгы баш тарту турында хатны яисә шартнамә проектын карап тикшерә һәм:

1) баш тарту турында хатны имзалый һәм әлеге хатны эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә җибәрә;

2) шартнамә проектын килештерә һәм аны килештерү өчен Башкарма комитетның архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсенә (алга таба – АШТһТҮИ) җибәрә.

Срок – 1 көн.

Процедураның нәтиҗәсе: имзаланган һәм эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә җибәрелгән баш тарту турында хат яисә килештерелгән һәм килештерү өчен АШТһТҮИга шартнамә проекты.

3.5.4. Эш кәгазьләрен алып бару идарәсе белгече баш тарту турында хатны терки һәм аны гариза бирүчегә җибәрә.

Срок – 1 көн.

Процедураның нәтиҗәсе: теркәлгән һәм гариза бирүчегә җибәрелгән баш тарту турында хат.

3.5.5. АШТһТҮИ шартнамә проектын карап тикшерә, килештерә һәм аны Башкарма комитетның хокук идарәсенә (алга таба – хокук идарәсенә) җибәрә яисә шартнамә проектындагы кимчелекләр буенча күрсәтмәләр әзерли һәм, әлеге кимчелекләрне бетерү өчен, ҖММИ бүлеге белгеченә җибәрә.

Срок – 3 көн.

Процедураның нәтиҗәсе: килештерелгән һәм килештерү өчен Хокук идарәсенә җибәрелгән шартнамә проектя яисә шартнамә проектындагы кимчелекләр буенча ҖММИ белгеченә җибәрелгән күрсәтмәләр.

3.5.6. АШТһТҮИ тарафыннан шартнамә проектындагы кимчелекләр буенча күрсәтмәләр җибәрелгән очракта, ҖММИ бүлеге белгече кимчелекләрне төзәтә һәм шартнамә проектын килештерү өчен АШТһТҮИга җибәрә.

Срок – 1 көн.

Процедураның нәтиҗәсе: төзәтелгән һәм килештерү өчен АШТһТҮИга җибәрелгән шартнамә проекты.

3.5.7. АШТһТҮИ төзәтелгән шартнамә проектын карап тикшерә, аны килештерә һәм килештерү өчен Хокук идарәсенә җибәрә.

Срок – 1 көн.

Процедураның нәтиҗәсе: килештерү өчен Хокук идарәсенә җибәрелгән шартнамә проекты.

3.5.8. Хокук идарәсе шартнамә проектын карап тикшерә, килештерә һәм ҖММИ башлыгына җибәрә.

Тапшырылган документлар норматив хокукый актларга туры килмәгән очракта, Хокук идарәсе шартнамә проектындагы кимчелекләр буенча күрсәтмәләр әзерли һәм әлеге кимчелекләрне төзәтү өчен ҖММИ бүлеге белгеченә җибәрә.

Срок – 4 көн.

Процедураның нәтиҗәсе: килештерелгән һәм ҖММИ башлыгына җибәрелгән шартнамә проекты яисә шартнамә проектындагы кимчелекләр буенча ҖММИ бүлеге белгеченә җибәрелгән күрсәтмәләр.

3.5.9. Хокук идарәсе тарафыннан шартнамә проектындагы кимчелекләр буенча күрсәтмәләр җибәрелгән очракта, ҖММИ бүлеге белгече кимчелекләрне төзәтә һәм шартнамә проектын алга таба килештерү өчен Хокук идарәсенә җибәрә.

Срок – 1 көн.

Процедураның нәтиҗәсе: төзәтелгән һәм килештерү өчен Хокук идарәсенә җибәрелгән шартнамә проекты.

3.5.10. Хокук идарәсе төзәтелгән шартнамә проектын карап тикшерә, аны килештерә һәм имзалау өчен Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасарына җибәрә.

Срок – 1 көн.

Процедураның нәтиҗәсе: Хокук идарәсе тарафыннан килештерелгән һәм имзалау өчен Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасарына җибәрелгән шартнамә проекты.

3.5.11. Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары шартнамә проектын кул имзалый һәм теркәү өчен ҖММИ бүлеге белгеченә җибәрә.

Срок – 1 көн.

Процедураның нәтиҗәсе: Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары тарафыннан имзаланган һәм теркәү өчен ҖММИ бүлеге белгеченә җибәрелгән шартнамә проекты.

3.5.12. ҖММИ бүлеге белгече шартнамә проектын терки һәм теркәлгән җир участогын сату-алу шартнамәсен гариза бирүчегә бирә.

Срок – 1 көн.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә бирелгән шартнамә.

3.5.13. Гариза бирүче җир участогын сату-алу шартнамәсе буенча, шартнамәдә күрсәтелгән исәп-хисап счетына акча (шартнамәдә күрсәтелгән сумманы) күчерә.

Әлеге процедураның срогы муниципаль хезмәт күрсәтү срогына керми.

Процедураның нәтиҗәсе: күчерелгән акча.

3.5.14. ҖММИ бүлеге белгече:

1) гариза бирүчедән акча күчерү турында мәгълүмат алып, 3 нөсхәдә җир участогын кабул итү-тапшыру актын төзи һәм имзалау өчен гариза бирүчегә бирә;

2) гариза бирүче тарафыннан җир участогын кабул итү-тапшыру акты имзаланганнннан соң, гариза бирүчегә 2 нөсхәдә җир участогын кабул итү-тапшыру актын бирә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гариза бирүче килгән көнне, чират тәртибендә, 30 минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә бирелгән җир участогын кабул итү-тапшыру акты.

3.6. КФҮ аша муниципаль хезмәт күрсәтү

3.6.1. Гариза бирүче муниципаль хезмәттән файдалану өчен КФҮгә мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

3.6.2. Муниципаль хезмәтне КФҮ аша күрсәтү, КФҮнең билгеләнгән тәртиптә расланган эш регламенты нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.6.3. Муниципаль хезмәттән файдалану өчен КФҮдән документлар кергәндә, процедуралар әлеге Регламентның 3.3-3.5.13 пунктлары нигезендә гамәлгә ашырыла. Муниципаль хезмәт нәтиҗәсе КФҮгә җибәрелә.

3.7. Техник хаталарны төзәтү.

3.7.1. Муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булган документта техник хата ачыкланган очракта, гариза бирүче Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә түбәндәгеләрне тапшыра:

техник хатаны төзәтү турында гариза (3 нче кушымта);

муниципаль хезмәт нәтиҗәсе буларак, гариза бирүчегә бирелгән техник хаталы документ;

техник хата булуны дәлилли торган юридик көчкә ия документлар.

Муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булган документта күрсәтелгән мәгълүматлардагы техник хатаны төзәтү турында гариза, гариза бирүче (вәкаләтле вәкил) тарафыннан шәхсән, яисә почта аша (шул исәптән электрон почта аша), яисә Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы яки КФҮ аша бирелә.

3.7.2. Эш кәгазьләрен алып бару идарәсе белгече техник хатаны төзәтү турында гаризаны кабул итә, теркәлгән документлары белән бергә гаризаны терки һәм аларны ҖММИ башлыгына тапшыра.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гариза теркәлгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән һәм карап тикшерү өчен ҖММИ башлыгына җибәрелгән гариза һәм документлар.

3.7.3. ҖММИ башлыгы гаризаны һәм документларны карап тикшерә һәм аларны ҖММИ бүлеге башлыгына җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гариза теркәлгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: карап тикшерү өчен ҖММИ бүлеге башлыгына җибәрелгән гариза һәм документлар.

3.7.4. ҖММИ бүлеге башлыгы гаризаны һәм документларны карап тикшерә, аларны ҖММИ бүлеге белгеченә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гариза теркәлгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: ҖММИ бүлеге белгеченә җибәрелгән гариза һәм документлар.

3.7.5. ҖММИ бүлеге белгече документларны карап тикшерә һәм муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булган шартнамәгә үзгәрешләр кертү максатында, әлеге Регламентның 3.5 пунктында каралган процедураларны гамәлгә ашыра һәм техник хата булган шартнамәнең төп нөсхәсен гариза бирүчедән (вәкаләтле вәкилдән) алгач, шәхсән имза куйдырып, төзәтелгән шартнамәне гариза бирүчегә (вәкаләтле вәкилгә) бирә яки, техник хаталы шартнамәнең төп нөсхәсен Башкарма комитетка биргән очракта, шартнамәне алу мөмкинлеге турында гариза бирүченең адресы буенча почта аша (электрон почта аша) хат җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура техник хата ачыкланганнан яки җибәрелгән хата турында теләсә кайсы кызыксынган заттан гариза алынганнан соң өч көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә бирелгән (җибәрелгән) шартнамә.

## 4. Муниципаль хезмәт күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм формалары

4.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту гариза бирүчеләрнең хокукларын бозу очракларын ачыклау һәм бетерүне, муниципаль хезмәт күрсәтү процедураларының үтәлешенә тикшерүләр үткәрү, Башкарма комитет вазыйфаи затларының карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) карарлар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедураларның үтәлешен контрольдә тоту формалары булып түбәндәгеләр тора:

1) муниципаль хезмәт күрсәтү буенча документлар проектларын тикшерү һәм килештерү; Тикшерү нәтиҗәсе булып проектларны визалау тора;

2) эш башкаруны алып баруга карата билгеләнгән тәртиптә үткәрелә торган тикшерүләр;

3) муниципаль хезмәт күрсәтү процедураларының үтәлеше буенча билгеләнгән тәртиптә контроль тикшерүләр үткәрү.

Контроль тикшерүләр планлы (Башкарма комитетның ярты еллык яки еллык эш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла) һәм планнан тыш булырга мөмкин. Тикшерүләр үткәргәндә муниципаль хезмәт күрсәтү (комплекслы тикшерүләр) белән бәйле, яки гариза бирүченең конкрет мөрәҗәгате буенча барлык мәсьәләләр каралырга мөмкин.

Муниципаль хезмәт күрсәткәндә һәм карарлар кабул иткәндә гамәлләрне контрольдә тотуны гамәлгә ашыру максатында Башкарма комитет Җитәкчесенә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре турында белешмә бирелә.

4.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча административ процедураларда билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеге үтәлешен агымдагы контрольдә тоту Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.3. Башкарма комитетның агымдагы контрольне гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларының исемлеге Башкарма комитетның структур бүлекчәләре турындагы нигезләмәләр һәм вазыйфаи инструкцияләр нигезендә билгеләнә.

Үткәрелгән тикшерүләрнең нәтиҗәләре буенча, гариза бирүчеләрнең хокукларын бозулар ачыкланган очракта, гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартылалар.

4.4. Башкарма комитет Җитәкчесе гариза бирүчеләрнең мөрәҗәгатьләре үз вакытында карап тикшерелмәү өчен җаваплы була.

Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары әлеге Регламентның 3 бүлегендә күрсәтелгән административ гамәлләрнең үз вакытында һәм (яки) тиешенчә үтәлмәве өчен җаваплы була.

Башкарма комитетның вазыйфаи затлары һәм башка муниципаль хезмәткәрләре муниципаль хезмәт күрсәтү барышында кабул ителә (гамәлгә ашырыла) торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) өчен законда билгеләнгән тәртиптә җаваплы булалар.

## 5. Муниципаль хезмәт күрсәтүче органнарның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе

5.1. Муниципаль хезмәттән файдаланучылар Башкарма комитетның муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы хезмәткәрләренең карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр тәртиптә Башкарма комитетка шикаять бирергә хокуклы.

Гариза бирүче шикаять белән мөрәҗәгать итәргә мөмкин, шул исәптән түбәндәге очракларда:

1) гариза бирүченең муниципаль хезмәт күрсәтү турында запросын теркәү срогын бозу;

2) муниципаль хезмәт күрсәтү срогын бозу;

3) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең норматив хокукый актларында каралмаган документларны таләп итү;

4) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең норматив хокукый актларында тапшыру каралган документларны кабул итүдән баш тарту;

5) баш тарту өчен нигезләр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Татарстан Республикасы Яр Чаллы

шәһәре муниципаль берәмлегенең норматив хокукый актларында каралмаган очракта, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту;

6) муниципаль хезмәт күрсәткәндә гариза бирүчедән Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп итү;

7) Башкарма комитетның, Башкарма комитет вазыйфаи затының, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән ялгышларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуы яисә андый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозу.

5.2. Шикаять язма рәвештә кәгазьдә яки электрон формада Башкарма комитетка һәм Башкарма комитет Җитәкчесенә бирелә.

Шикаять почта аша, КФҮ аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтыннан (http://www.nabchelny.tatar.ru), Татарстан Республикасының бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (http://uslugi.tatar.ru), Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталыннан (http://www.gosuslugi.ru) файдаланып җибәрелергә мөмкин, шулай ук гариза бирүчене шәхси кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин.

5.3. Шикаятьне карап тикшерү срогы – ул теркәлгән көннән башлап унбиш эш көне эчендә. Башкарма комитетның, Башкарма комитет вазыйфаи затының гариза бирүчедән документларны кабул итүдән яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуыннан риза булмыйча шикаять бирелгән очракта яки шундый төзәтүләрнең билгеләнгән срогы бозылудан риза булмыйча шикаять бирелгән очракта – ул теркәлгән көннән башлап биш эш көне эчендә.

5.4. Шикаятьтә түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять бирелә торган Башкарма комитетның, Башкарма комитет вазыйфаи затының яки Башкарма комитет муниципаль хезмәткәренең исеме;

2) гариза бирүченең – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), яшәү урыны турында мәгълүматлар яисә гариза бирүченең – юридик затның урнашу урыны турында мәгълүматлар, шулай ук элемтә өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы (булган очракта) һәм гариза бирүчегә җавап җибәрелергә тиешле почта адресы;

3) Башкарма комитетның, Башкарма комитет вазыйфаи затының яки Башкарма комитет муниципаль хезмәткәренең шикаять бирелә торган карарлары, гамәлләре (гамәл кылмавы) турында мәгълүмат;

4) гариза бирүченең Башкарма комитетның, Башкарма комитет вазыйфаи затының яисә Башкарма комитетның муниципаль хезмәткәренең карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән нинди нигездә килешмәвенең дәлилләре.

5.5. Шикаятькә шикаятьтә бәян ителгән хәлләрне раслаучы документларның күчермәләре теркәлергә мөмкин. Бу очракта шикаятьтә аңа теркәлә торган документлар исемлеге язып куела.

5.6. Шикаять аны биргән муниципаль хезмәттән файдаланучы тарафыннан имзалана.

5.7. Шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча Башкарма комитет Җитәкчесе (аны алмаштыручы зат) түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) шикаять канәгатьләндерә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда Башкарма комитет тарафыннан җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, Россия Федерациясенең норматив хокукый

актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда түләтү каралмаган акчаларны гариза бирүчегә кире кайтару рәвешендә, шулай ук башка рәвештә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарта.

5.8. Әлеге Регламентның 5.7 пунктында күрсәтелгән карар кабул ителгән көннең икенче көненнән дә соңга калмый, гариза бирүчегә язма рәвештә һәм гариза бирүченең теләге буенча электрон рәвештә шикаятьләрне карап тикшерү нәтиҗәләре турында дәлилләнгән җавап җибәрелә.

5.9. Шикаять тулысынча яки өлешчә канәгатьләндерелгән очракта Башкарма комитет Җитәкчесе кимчелекләрне бетерү максатларында күрелергә тиешле чараларны билгели. Шикаятьне карап тикшерү барышында яки аның нәтиҗәләре буенча административ хокук бозулар яки җинаять составы билгеләре ачыкланган очракта, Башкарма комитет Җитәкчесе булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

5.10. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи затның карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата Россия Федерациясенең гражданлык һәм арбитраж процессуаль законнарында билгеләнгән тәртиптә судта шикаять бирелергә мөмкин.

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе — Г.К. Әхмәтова

Муниципаль милектәге җир участогын сатулар үткәрмичә сату буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына
1 нче кушымта

Россия Федерациясе Җир кодексыннан өземтә

39.3 статья. Дәүләт яки муниципаль милектәге җир участокларын сатуларда һәм сатулар үткәрмичә сату очраклары

2. Сатулар үткәрмичә түбәндәгеләрне сату гамәлгә ашырыла:

1) территорияне комплекслы үзләштерү өчен арендага бирелгән җир участогыннан барлыкка килгән җир участокларын (эконом класслы торак төзү максатларында территорияне комплекслы үзләштерү өчен, мондый торак төзү максатларында территорияне комплекслы үзләштерү турында шартнамә төзегән юридик затка бирелгән җир участогыннан барлыкка килгән җир участокларыннан тыш) Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә территорияне комплекслы үзләштерү турында шартнамә төзегән затка, әгәр әлеге пунктның 2 һәм 4 пунктчаларында башкача каралмаган булса;

2) индивидуаль торак төзү максатларында территорияне комплекслы үзләштерү өчен гражданнар тарафыннан төзелгән коммерцияле булмаган оешмага бирелгән җир участогыннан барлыкка килгән җир участокларын (гомуми файдаланудагы мөлкәткә караган җир участокларыннан тыш), әлеге коммерцияле булмаган оешма әгъзаларына яки, әгәр әлеге коммерцияле булмаган оешма әгъзаларының гомуми җыелышы карарында күздә тотылган булса, әлеге коммерцияле булмаган оешмага;

3) бакчачылык, яшелчәчелек, дача хуҗалыгы алып бару өчен гражданнар тарафыннан төзелгән коммерцияле булмаган оешмага бирелгән җир участогыннан барлыкка килгән җир участокларын (гомуми файдаланудагы мөлкәткә караган җир участокларыннан тыш) әлеге коммерцияле булмаган оешма әгъзаларына;

4) индивидуаль торак төзү максатларында территорияне комплекслы үзләштерү өчен гражданнар тарафыннан төзелгән коммерцияле булмаган оешмага бирелгән һәм гомуми файдаланудагы мөлкәткә караган җир участогын бүлү нәтиҗәсендә барлыкка килгән җир участогын әлеге коммерцияле булмаган оешмага;

5) дача хуҗалыгы алып бару өчен юридик затка бирелгән һәм гомуми файдаланудагы мөлкәткә караган җир участогын бүлү нәтиҗәсендә барлыкка килгән җир участокларын күрсәтелгән юридик затка;

6) РФ Җир кодексының 39.20 статьясында каралган очракларда, биналар, корылмалар урнашкан җир участокларын шундый биналар, корылмалар яисә алар эчендәге бүлмәләр милекчеләренә;

7) юридик затларның даими (сроксыз) файдалануында булган җир участокларын күрсәтелгән юридик затларга (РФ Җир кодексының 39.9 статьясының 2 пунктында күрсәтелгән затлардан тыш);

8) җир участокларын крестьян (фермер) хуҗалыгына яки «Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр әйләнеше турында» Федераль законда билгеләнгән очракларда авыл хуҗалыгы оешмасына;

9) авыл хуҗалыгы производствосын алып бару өчен билгеләнгән һәм гражданга яки юридик затка арендага бирелгән җир участокларын, әгәр әлеге граждан яки әлеге юридик зат тарафыннан мондый җир участогын сатып алу-сату шартнамәсе төзү турында гариза сатуларны үткәрмичә, җир участогын арендалау буенча күрсәтелгән шартнамәнең срогы чыккан көнгә кадәр бирелгән очракта, мондый җир участогыннан тиешенчә файдалангану шарты белән, әлеге граждан яки әлеге юридик зат белән аренда шартнамәсе төзелгән яисә әлеге гражданга яки әлеге юридик затка җир участогын арендалау шартнамәсе буенча хокук һәм бурычларны тапшыру вакыттан башлап өч ел узгач бу гражданга яки бу юридик затка;

10) РФ Җир кодексының 39.18 статьясы нигезендә җир участокларын индивидуаль торак төзү, торак пункт чикләрендә шәхси ярдәмче хуҗалык, бакчачылык, дача хуҗалыгы алып бару өчен гражданнарга, крестьян (фермер) хуҗалыгы тарафыннан аның эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен гражданнарга яки крестьян (фермер) хуҗалыкларына.

Муниципаль милектәге җир участогын сатулар үткәрмичә сату буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына 2 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенә
______________________________________________
кемнән ____________________________________________
(физик затлар өчен - фамилиясе, исеме, атасының исеме, гариза бирүченең яшәү урыны һәм гариза бирүченең шәхесен раслаучы документ реквизитлары)
__________________________________________
(юридик затлар өчен – гариза бирүченең исеме һәм урнашу урыны, ЕГРЮЛда юридик затны дәүләт теркәвенә алу турында язманың дәүләт теркәү номеры, ИНН, гариза бирүче булып чит ил юридик заты торган очрактан тыш)
___________________________________________________
___________________________________________________
(почта адрес һәм (яки) электрон почта адресы, элемтә өчен телефон номеры)

Җир участогын сатулар үткәрмичә сату турында
гариза

Сездән, ________________________________________________________ нигезендә,
(РФ Җир кодексының 39.3 статьясының 2 пунктында каралган нигез күрсәтелә)
_____________________________________________________________________ өчен,
(җир участогыннан файдалану максаты күрсәтелә)

мәйданы ___________ кв.м., кадастр номеры _________________________, рөхсәт ителгән файдалану төре ___________________, _______________________ җирләр категориясеннән булган, ______________ муниципаль районы (шәһәр округы), ____________ торак пункты, ___________________ урамы, ______ йорт адресы буенча урнашкан җир участогын сатулар үткәрмичә милек хокукында милеккә бирүне сорыйм.

Өстәмә мәгълүматлар (түбәндә күрсәтелгән шартлар үтәлгәндә тутырыла):
________________________________________________________________________
җир участогы дәүләт яки муниципаль ихтыяҗлар өчен алына торган җир участогына алмашка бирелгән очракта, дәүләт яки муниципаль ихтыяҗлар өчен җир участогын алу турында карар реквизитлары;

________________________________________________________________________________

җир участогы әлеге документта һәм (яки) әлеге проектта каралган объектларны урнаштыру өчен бирелгән очракта, территориаль планлаштыру документын һәм (яки) территорияне планлаштыру проектын раслау турындагы карар реквизитлары;

________________________________________________________________________________

сорала торган җир участогы әлеге карар нигезендә барлыкка китерелгән яки аның чикләре төгәлләштерелгән очракта, җир участогы бирүне алдан килештерү турында карар реквизитлары.

Гаризага түбәндәге документлар (сканерланган күчермәләр) теркәлә:

1) шәхесне раслаучы документ күчермәсе (физик затлар);

2) Гариза белән гариза бирүченең вәкиле мөрәҗәгать иткән очракта, гариза бирүче вәкиленең вәкаләтләрен раслаучы документ;

3) гариза бирүче булып чит ил юридик заты торган очракта, чит ил дәүләте законнары нигезендә юридик затны дәүләт теркәвенә алу турындагы документларның таныкланган рус теленә тәрҗемәсе.

Персональ мәгълүматларны эшкәртүгә (җыюга, системалаштыруга, туплауга, саклауга, аныклауга (яңартуга, үзгәртүгә), файдалануга, таратуга (шул исәптән тапшыруга), блокировкалауга, персональ мәгълүматларны юкка чыгаруга, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтү кысаларында персональ мәгълүматларны эшкәртү өчен кирәкле булган башка төрле гамәлләргә), шул исәптән автоматлаштырылган режимда, муниципаль хезмәт күрсәтү максатларында муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан алар нигезендә карарлар кабул итүне дә кертеп, үземнең ризалыгымны, шулай ук минем тарафтан күрсәтелгән затның ризалыгын раслыйм.

Моның белән раслыйм: әлеге гаризага кертелгән, шәхесемә һәм минем тарафтан тәкъдим ителгән затка кагылышлы, шулай ук минем тарафтан түбәндә кертелгән мәгълүматлар дөрес. Гаризага теркәлгән документлар (документларның сканерланган күчермәләре) Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән таләпләргә туры килә; гариза бирелгән вакытка әлеге документлар гамәлдә һәм андагы мәгълүматлар дөрес.

Миңа күрсәтелгән муниципаль хезмәтнең сыйфатын бәяләү буенча _____________________ телефоны аша сораштыруда катнашырга ризалыгымны бирәм.

______________          _________________ ( ________________)

(дата)          (имза)          (Ф.И.А.и.)

Муниципаль милектәге җир участогын сатулар үткәрмичә сату буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына
3 нче кушымта

Гариза бирүченең җир участогын сатулар үткәрмичә түләү нигезендә милеккә сатып алу хокукын раслаучы документлар исемлегеннән өземтә торгов

| Т/с | Сатулар үткәрмичә җир участогы бирү нигезе | Гариза бирүче | Җир участогы | Гариза бирүченең җир участогын сатулар үткәрмичә, түләү нигезендә милеккә сатып алу хокукын раслаучы һәм җир участогына хокукларны сатып алу турында гаризага теркәлә торган документлар[1] |
|---|---|---|---|---|
| 1. | РФ Җир кодексының 39.3 статьясындагы 2 пунктның 1 пунктчасы | Территорияне комплекслы үзләштерү турында шартнамә төзегән юридик зат | Территорияне комплекслы үзләштерү өчен арендага бирелгән җир участогыннан барлыкка килгән җир участогы | *Территорияне комплекслы үзләштерү турында шартнамә<br><br>* Сорала торган җир участогының кадастр паспорты яисә сорала торган җир участогы турында кадастр өземтәсе<br><br>* Сатып алына торган җир участогына хокуклар турында Бердәм дәүләт күчемсез милеккә хокуклар һәм алар белән килешүләр төзү реестрыннан (ЕГРП) өземтә (дәүләт милке чикләнмәгән җир участоклары барлыкка килгән очраклардан тыш) яки күрсәтелгән җир участогына теркәлгән хокуклар турында сорала торган мәгълүматлар ЕГРПта булмау турында белдерү кәгазе<br><br>* Планлаштыруның расланган проекты һәм территорияне межалауның расланган проекты<br><br>* Гариза бирүче булып торган юридик зат турында Бердәм |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | дәүләт юридик затлар реестрыннан (ЕГРЮЛ) өземтә |
| 2. | РФ Җир кодексының 39.3 статьясындагы 2 пунктның 2 пунктчасы | Индивидуаль торак төзү максатларында территорияне комплекслы үзләштерү өчен җир участогы бирелгән гражданнар тарафыннан төзелгән коммерцияле булмаган оешма әгъзасы | Индивидуаль торак төзү максатларында территорияне комплекслы үзләштерү өчен гражданнар тарафыннан төзелгән коммерцияле булмаган оешмага бирелгән җир участогыннан барлыкка килгән җир участогы | Гариза бирүченең коммерцияле булмаган оешма әгъзасы булуны раслаучы документ<br><br>Коммерцияле булмаган оешма органының сорала торган җир участогын гариза бирүчегә бирү турында карары<br><br>*Территорияне комплекслы үзләштерү турында шартнамә<br><br>* Сорала торган җир участогының кадастр паспорты яисә сорала торган җир участогы турында кадастр өземтәсе<br><br>* Сатып алына торган җир участогына хокуклар турында ЕГРПтан өземтә (дәүләт милке чикләнмәгән җир участоклары барлыкка килгән очраклардан тыш) яки күрсәтелгән җир участогына теркәлгән хокуклар турында сорала торган мәгълүматлар ЕГРПта булмау турында белдерү кәгазе<br><br>* Гариза бирүче булып торган юридик зат турында ЕГРЮЛдан өземтә |
| 3. | РФ Җир кодексының 39.3 статьясындагы 2 пунктның 3 пунктчасы | Бакчачылык, яшелчәчелек, дача хуҗалыгы алып бару өчен җир участогы бирелгән гражданнар тарафыннан төзелгән коммерцияле булмаган оешма әгъзасы | Бакчачылык, яшелчәчелек, дача хуҗалыгы алып бару өчен гражданнар тарафыннан төзелгән коммерцияле булмаган оешмага бирелгән җир участогыннан барлыкка килгән, бакчачылык яки яшелчәчелек өчен | Мондый җир участогына хокук ЕГРПта теркәлмәгән булса, гариза бирүченең сорала торган җир участогына хокукын раслаучы (билгеләүче) документлар<br><br>Гариза бирүченең коммерцияле булмаган оешма әгъзасы булуны раслаучы документ<br><br>Коммерцияле булмаган оешма органының җир участогын гариза бирүчегә бирү турында карары<br><br>* Территорияне межалауның расланган проекты<br><br>* Коммерцияле булмаган берләшмә территориясен оештыру һәм төзү проекты (территорияне межалауның расланган |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | билгеләнгән җир участогы | проекты булмаган очракта)<br><br>* Сорала торган җир участогының кадастр паспорты яисә сорала торган җир участогы турында кадастр өземтәсе<br><br>* Сатып алына торган җир участогына хокуклар турында ЕГРПтан өземтә (дәүләт милке чикләнмәгән җир участоклары барлыкка килгән очраклардан тыш) яки күрсәтелгән җир участогына теркәлгән хокуклар турында сорала торган мәгълүматлар ЕГРПта булмау турында белдерү кәгазе<br><br>* Гариза бирүче булып торган юридик зат турында ЕГРЮЛдан өземтә |
| 4. | РФ Җир кодексының 39.3 статьясындагы 2 пунктның 4 пунктчасы | Индивидуаль торак төзү максатларында территорияне комплекслы үзләштерү өчен җир участогы бирелгән гражданнар тарафыннан төзелгән коммерцияле булмаган оешма | Индивидуаль торак төзү максатларында территорияне комплекслы үзләштерү өчен гражданнар тарафыннан төзелгән коммерцияле булмаган оешмага бирелгән һәм гомуми файдаланудагы мөлкәткә караган җир участогын бүлү нәтиҗәсендә барлыкка килгән җир участогы | Коммерцияле булмаган оешма органының гомуми файдаланудагы мөлкәткә кагылышлы җир участогын сатып алу турында карары<br><br>*Территорияне комплекслы үзләштерү турында шартнамә<br><br>* Сорала торган җир участогының кадастр паспорты яисә сорала торган җир участогы турында кадастр өземтәсе<br><br>* Сатып алына торган җир участогына хокуклар турында ЕГРПтан өземтә (дәүләт милке чикләнмәгән җир участоклары барлыкка килгән очраклардан тыш) яки күрсәтелгән җир участогына теркәлгән хокуклар турында сорала торган мәгълүматлар ЕГРПта булмау турында белдерү кәгазе<br><br>* Гариза бирүче булып торган юридик зат турында ЕГРЮЛдан өземтә |
| 5. | РФ Җир кодексының 39.3 статьясындагы | Дача хуҗалыгы | Дача хуҗалыгы | Юридик зат органының гомуми файдаланудагы мөлкәткә кагылышлы җир участогын сатып алу турында карары |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | 2 пунктның<br>5 пунктчасы | алып бару өчен җир участогы бирелгән юридик зат | алып бару өчен юридик затка бирелгән һәм гомуми файдаланудагы мөлкәткә караган җир участогын бүлү нәтиҗәсендә барлыкка килгән җир участогы | Мондый җир участогына хокук ЕГРПта теркәлмәгән булса, гариза бирүченең сорала торган җир участогына хокукын раслаучы (билгеләүче) документлар<br><br>* Территорияне межалауның расланган проекты<br><br>* Коммерцияле булмаган берләшмә территориясен оештыру һәм төзү проекты (территорияне межалауның расланган проекты булмаган очракта)<br><br>* Сорала торган җир участогының кадастр паспорты яисә сорала торган җир участогы турында кадастр өземтәсе<br><br>* Сатып алына торган җир участогына хокуклар турында ЕГРПтан өземтә (дәүләт милке чикләнмәгән җир участоклары барлыкка килгән очраклардан тыш) яки күрсәтелгән җир участогына теркәлгән хокуклар турында сорала торган мәгълүматлар ЕГРПта булмау турында белдерү кәгазе<br><br>* Гариза бирүче булып торган юридик зат турында ЕГРЮЛдан өземтә |
| 6. | РФ Җир кодексының 39.3 статьясындагы<br>2 пунктның<br>6 пунктчасы | Бина, корылма яисә бина, корылма эчендәге бүлмә милекче | Бина, корылма урнашкан җир участогы | Мондый бинага, корылмага яисә бүлмәгә хокук ЕГРПта теркәлмәгән булса, гариза бирүченең бинага, корылмага яисә бүлмәгә хокукларын раслаучы (билгеләүче) документ<br><br>Мондый җир участогына хокук ЕГРПта теркәлмәгән булса, гариза бирүченең сорала торган җир участогына хокукларын раслаучы (билгеләүче) документ<br><br>Гариза бирүченең (гариза бирүчеләрнең) сорала торган җир участогында урнашкан барлык биналар, корылмалар исемлеген үз эченә алган, кадастр (шартлы, инвентарь) номерлары һәм адрес ориентирлары күрсәтелгән хәбәре<br><br>* Сорала торган җир участогының кадастр паспорты яисә сорала торган җир участогы турында кадастр өземтәсе |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | * Сорала торган җир участогында урнашкан бинаның, корылманың кадастр паспорты<br><br>* Сорала торган җир участогында урнашкан бинадагы, корылмадагы бүлмә милекчесе мөрәҗәгать иткән очракта, бүлмәнең кадастр паспорты<br><br>* Сатып алына торган җир участогына һәм анда урнашкан күчемсез милек объектларына хокуклар турында ЕГРПтан өземтә яисә сорала торган мәгълүматлар ЕГРПта булмау турында белдерү кәгазе<br><br>* Гариза бирүче булып торган юридик зат турында ЕГРЮЛдан өземтә<br><br>* Гариза бирүче булып торган шәхси эшмәкәр турында ЕГРИПтан өземтә |
| 7. | РФ Җир кодексының 39.3 статьясындагы 2 пунктның 7 пунктчасы | Җир участогыннын даими (сроксыз) файдалану хокукында файдаланучы юридик зат | Юридик затның даими (сроксыз) файдалану хокукында булган җир участогы | Мондый җир участогына хокук ЕГРПта теркәлмәгән булса, гариза бирүченең сорала торган җир участогына хокукын раслаучы (билгеләүче) документлар<br><br>* Сорала торган җир участогының кадастр паспорты яисә сорала торган җир участогы турында кадастр өземтәсе<br><br>* Сатып алына торган җир участогына хокуклар турында ЕГРПтан өземтә яки күрсәтелгән җир участогына теркәлгән хокуклар турында сорала торган мәгълүматлар ЕГРПта булмау турында белдерү кәгазе<br><br>* Гариза бирүче булып торган юридик зат турында ЕГРЮЛдан өземтә |
| 8. | РФ Җир кодексының 39.3 статьясындагы 2 пунктның 10 пунктчасы | Торак пункт, бакчачылык чикләрендә индивидуаль торак | Индивидуаль торак төзелеше, торак пункт, бакчачылык чикләрендә шәхси | * Сорала торган җир участогының кадастр паспорты яисә сорала торган җир участогы турында кадастр өземтәсе (гариза бирүче гаризада җир участогының кадастр номерын күрсәткән очракта) |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | төзелеше, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен җир участогы бирү турында һәм җир участогы бирүне алдан килештерү турында гариза биргән граждан | ярдәмче хуҗалык алып бару өчен билгеләнгән җир участогы | * Сатып алына торган җир участогына хокуклар турында ЕГРПтан өземтә яки күрсәтелгән җир участогына теркәлгән хокуклар турында сорала торган мәгълүматлар ЕГРПта булмау турында белдерү кәгазе |

[1] Документлар төп нөсхәдә (әгәр документлар һәркем файдалану өчен мөмкин булган булса, күчермәләрдә) яисә җир участогына хокук алу турында гариза кабул итүче башкарма хакимият органының яки җирле үзидарә органының вазыйфаи заты тарафыннан раслана торган күчермәләрдә тапшырыла (җибәрелә).

* Документлар дәүләт яки муниципаль милектәге җир участоклары белән эш итүгә вәкаләтле органнар карамагында яисә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек аша ҖММИ тарафыннан соратып алына.

Муниципаль милектәге җир участогын сатулар үткәрмичә сату буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына 4 нче кушымта

## Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча эзлеклелек блок-схемасы

Гариза бирүче муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза бирә һәм әлеге Регламентның 2.5 пункты нигезендә документлар тапшыра

Гариза һәм документлар

Эш кәгазьләрен алып бару идарәсе белгече гамәлгә ашыра:
гаризаны кабул итүне һәм теркәүне
- документларны кабул итү датасы турында билге куеп, гариза бирүчегә гариза күчермәсен тапшыруны;
- карап тикшерү өчен, гаризаны һәм документларны Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрүне

Эш кәгазьләрен алып бару идарәсе белгече гариза бирүчегә гаризаны теркәү өчен каршылыклар булу турында хәбәр итә һәм, гаризаны кире кайтару сәбәпләрен күрсәтеп, документларны гариза

Гариза бирүчегә кире кайтарылган гариза һәм документлар

кабул ителгән һәм теркәлгән, карап тикшерү өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрелгән гариза һәм документлар

Башкарма комитет Җитәкчесе гаризаны һәм документларны карап тикшерә һәм Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасарына җибәрә

карап тикшерү өчен Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасарына җибәрелгән гариза һәм документлар

Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары гаризаны һәм документларны карап тикшерә, аларны ҖММИ башлыгына җибәрә

ҖММИ башлыгына җибәрелгән гариза һәм документлар

ҖММИ башлыгы гаризаны һәм документларны карап тикшерә, аларны ҖММИ бүлеге башлыгына җибәрә

ҖММИ бүлеге башлыгына җибәрелгән гариза һәм документлар

ҖММИ бүлеге башлыгы гаризаны һәм документларны карап тикшерә, аларны ҖММИ бүлеге белгеченә җибәрә

ҖММИ бүлеге белгеченә җибәрелгән гариза һәм документлар

ҖММИ бүлеге белгече, норматив хокукый базаны исәпкә алып, гаризаны һәм документларны карап тикшерә, әлеге Регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән документларны бирү турында запрос формалаштыра һәм ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы ярдәмендә электрон формада җибәрә

Мәгълүмат белән тәэмин итүчеләрнең белгечләре запрослар нигезендә соралган документларны бирәләр

ҖММИ бүлеге белгече кергән документлар нигезендә карар проектын әзерләүне гамәлгә ашыра һәм килештерү өчен ҖММИ бүлеге башлыгына җибәрә

Җир участогын сату-алу шартнамәсе проекты (алга таба - шартнамә проекты)

Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында хат (алга таба - баш тарту турында хат)

ҖММИ бүлеге башлыгы баш тарту турында хатны карап тикшерә, килештерә һәм имзалау өчен ҖММИ башлыгына җибәрә яисә шартнамә проектын килештерә һәм килештерү өчен ҖММИ башлыгына җибәрә.

ҖММИ башлыгына имзалау өчен җибәрелгән баш тарту турында хат яисә килештерү өчен җибәрелгән шартнамә проекты

ҖММИ башлыгы баш тарту турында хатны имзалый һәм эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә җибәрә

Имзаланган һәм эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә җибәрелгән баш тарту турында хат

ҖММИ башлыгы шартнамә проектын килештерә һәм килештерү өчен АШТһТҮИга җибәрә

Килештерү өчен АШТһТҮИга җибәрелгән шартнамә проекты

АШТһТҮИ шартнамә проектын килештерә һәм Хокук идарәсенә җибәрә, яисә шартнамә проектындагы кимчелекләр буенча күрсәтмәләр әзерли һәм ҖММИ бүлеге белгеченә җибәрә

Килештерелгән һәм Хокук идарәсенә җибәрелгән шартнамә проекты

ҖММИ бүлеге белгече шартнамә проектындагы кимчелекләрне төзәтә һәм АШТһТҮИга җибәрә


Хокук идарәсе шартнамә проектын карап тикшерә, килештерә һәм ҖММИ башлыгына җибәрә яисә күрсәтмәләр әзерли һәм ҖММИ бүлеге белгеченә җибәрә.
ҖММИ башлыгына җибәрелгән шартнамә проекты
ҖММИ бүлеге белгече Хокук идарәсе күрсәткән шартнамә проектындагы кимчелекләрне төзәтә һәм Хокук идарәсенә җибәрә
ҖММИ башлыгы шартнамә проектын карап тикшерә һәм килештерә һәм имзалау өчен Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасарына җибәрә
Килештерелгән һәм имзалау өчен Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасарына җибәрелгән шартнамә проекты
Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары шартнамә проектын имзалый һәм теркәү өчен ҖММИ бүлеге белгеченә җибәрә
Имзаланган һәм ҖММИ бүлеге белгеченә җибәрелгән шартнамә проекты
ҖММИ бүлеге белгече шартнамә проектын терки һәм теркәлгән җир участогын сату-алу турында шартнамәне гариза бирүчегә бирә
Теркәлгән һәм гариза бирүчегә бирелгән җир участогын сату-алу турында шартнамә
Гариза бирүче, җир участогын сату-алу шартнамәсе буенча, шартнамәдә күрсәтелгән исәп-хисап счетына акча күчерә
Күчерелгән акча
ҖММИ бүлеге белгече җир участогын кабул итү-тапшыру актын төзи һәм, гариза бирүченең үзе тарафыннан кабул итү-тапшыру актлары имзалаганнан соң, имзалау өчен гариза бирүчегә бирә һәм әлеге актны 3 нөсхәдә гариза бирүчегә бирә.
Гариза бирүчегә бирелгән җир участогын кабул итү-тапшыру акты

Муниципаль милектәге җир участогын сатулар үткәрмичә сату буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына
5 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре
Башкарма комитеты Җитәкчесенә

кемнән:_________________________

Техник хатаны төзәтү турында
гариза

Муниципаль хезмәт күрсәткәндә җибәрелгән хата турында хәбәр итәм _________________________________________________________________

(хезмәтнең исеме)

Язылган ______________________________________________________________________
_____________________________________________________________________________

Дөрес мәгълүматлар:___________________________________________________________
_____________________________________________________________________________

Җибәрелгән техник хатаны төзәтүне һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булып торган документка тиешле үзгәрешләр кертүне сорыйм.

Түбәндәге документларны терким:

1.
2.
3.

Техник хатаны төзәтү турында гаризаны кире кагу турында карар кабул ителгән очракта, әлеге карарны җибәрүне сорыйм:

электрон документны E-mail адресы: ___________ җибәрү юлы белән;

- расланган күчермә рәвешендә кәгазь чыганакта почта аша түбәдәге адрес буенча: ____________________________________________________________.

Персональ мәгълүматларны эшкәртүгә (җыюга, системалаштыруга, туплауга, саклауга, аныклауга (яңартуга, үзгәртүгә), файдалануга, таратуга (шул исәптән тапшыруга), блокировкалауга, персональ мәгълүматларны юкка чыгаруга, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтү кысаларында персональ мәгълүматларны эшкәртү өчен кирәкле булган башка төрле гамәлләргә), шул исәптән автоматлаштырылган режимда, муниципаль хезмәт күрсәтү максатларында муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан алар нигезендә карарлар кабул итүне дә кертеп, үземнең ризалыгымны, шулай ук минем тарафтан күрсәтелгән затның ризалыгын раслыйм.

Моның белән раслыйм: әлеге гаризага кертелгән, шәхесемә һәм минем тарафтан тәкъдим ителгән затка кагылышлы, шулай ук минем тарафтан түбәндә кертелгән мәгълүматлар дөрес. Гаризага теркәлгән документлар (документларның күчермәләре) Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән таләпләргә туры килә; гариза бирелгән вакытка әлеге документлар гамәлдә һәм андагы

мәгълүматлар дөрес.

Миңа күрсәтелгән муниципаль хезмәтнең сыйфатын бәяләү буенча ______________________ телефоны аша сораштыруда катнашырга ризалыгымны бирәм.

_______________ ___________________ ( _________________)
(дата) (имза) (Ф.И.А.и.)

Кушымта
(белешмә)

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Башкарма комитет Җитәкчесе | 30-55-42 | |
| Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе | 30-55-25 | |
| Җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы | 30-55-54 | |
| ҖММИ бүлеге башлыгы | 30-57-18 | |
| ҖММИ бүлеге белгече | 30-57-11 | |